ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

03.02.2021 г. Заинск № 57

**Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында**

Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Үз көчен югалткан дип танырга:

1.1. "Зәй муниципаль районы территориясе чикләрендә территориаль иҗтимагый үзидарәләр эшчәнлеген гамәлгә ашыру чыгымнарын компенсацияләү өчен Зәй муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында" 2014 елның 08 августындагы 1707 номерлы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарын;

1.2. "Зәй муниципаль районы бюджетыннан Зәй муниципаль районы муниципаль унитар предприятиеләрен тотуга бәйле чыгымнарны финанс ягыннан тәэмин итү максатларында субсидияләр бирү тәртибен раслау турында" 2020 елның 29 апрелендәге 186 номерлы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарын.

2. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә әлеге карарны Зәй муниципаль районының http://zainsk.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында урнаштырырга.

3. Карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисади үсеш, сәнәгать, сәүдә, эшмәкәрлеккә ярдәм буенча урынбасарына йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**